РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 21 » 12 2020 г. №947

Социаль наем килешүләре һәм дәүләт яки муниципаль торак фондына караган торак урыннарга наем килешүләре буенча торак урыннарны яллаучылар, шулай ук күп фатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында һәм (яки) гомуми җыелышта торак урыннарны карап тоту буенча түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күп фатирлы йортлардагы торак урыннар хуҗалары өчен торак урыннарны карап тотуга һәм ремонтлауга 2021 елга түләү күләмен раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күпфатирлы йортта гомуми милекне карап тоту кагыйдәләрен һәм күпфатирлы йортта сыйфатсыз һәм (яки) тоткарлык белән гомуми мөлкәтне карап тоту һәм хезмәтләр күрсәтү һәм күпфатирлы йортта гомуми милекне карап тоту һәм ремонтлау буенча эшләр башкару очрагында торак урынын карап тоту өчен түләү күләмен үзгәртү кагыйдәләрен раслау турында " 2006 елның 13 августындагы 491 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында «2004 ел, 28 июль, 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 3 декабрь, №1097 “Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми милекне капиталь ремонтлау өчен кертемнең минималь күләмен билгеләү турында 2013 ел, 29 июнь, 450 нче карарына үзгәрешләр кертү турында» Карары, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Советының 2020 елның 28

апрелендәге 18 номерлы карары белән кабул ителгән , “Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 2006 елның 12 гыйнварындагы 1 номерлы карары белән расланган Нигезләмәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1.2021 елның 1 гыйнварыннан билгеләргә:

- №1 кушымта нигезендә, муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондыннан торак урыннарын наем шартнамәләре буенча торак урыннарын яллаучылар өчен торак урыныннан файдаланган өчен түләү (наем өчен түләү) күләмен;

- №2 кушымта нигезендә, социаль наем килешүе һәм дәүләт яки муниципаль торак фондына караган торак урыннарга наем килешүе буенча торак урыннарны яллаучылар, шулай ук күп фатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында һәм (яки) гомуми җыелышта, хезмәт күрсәтү төрләреннән чыгып, торак урыннарны карап тотуга түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күп фатирлы йортлардагы торак урын хуҗалары өчен торак урыннарны карап тотуга түләү күләмен (календарь буенча бүлеп) расларга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкчесе С. П. Самонина

А. М. Магамедова

2-74-97

Кушымта 1
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты карары
белән расланды
№ ___ _____________ 2020 ел

**Социаль наем килешүләре һәм муниципаль торак фондына караган торак урыннарга наем килешүләре буенча торак урыннарны яллаучылар, шулай ук күп фатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында һәм (яки) гомуми җыелышта торак урыннарны карап тоту буенча түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күп фатирлы йорттагы торак урыннар хуҗалары өчен торак урыннарны карап тотуга һәм ремонтлауга түләү күләме**

| Хезмәт төре | Үлчәү берәмлеге | 2021елга тариф (2021 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәр) |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Торак фонды белән идарә итү | сум/м$^2$ | 1,54 |
| Йорт яны территориясен җыештыру | сум/м$^2$ | 1,85 |
| Торак бинаны ремонтлау һәм территорияне төзекләндерү | сум/м$^2$ | 3,53 |
| Йорт эчендәге инженерлык челтәрләренә агымдагы ремонт һәм аларны тиешле дәрәҗәдә тоту: | сум/м$^2$ | |
| суүткәргеч-канализация челтәрләрен | | *2,26* |
| Газ белән тәэмин итүнең фасад һәм йорт эче челтәрләрен | | *0,35* |
| Электр белән тәэмин итү челтәрләрен | | *1,27* |
| Капиталь ремонт | сум/м$^2$ | 6,11 |

Кушымта 1
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты карары
белән расланды
№ ___ _______________ 2020 ел

**2021 елга торак урын яллауга база ставкасы**
**(торак урыннары яллаучылар өчен)**

| **Түләү төре** | **Үлчәү берәмлеге** | **Түләү күләме** |
|---|---|---|
| Муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре һәм торак урыннарын наем шартнамәләре буенча торак урыннан файдаланган өчен түләү | сум/кв.м. | 7,15 |